# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирел авыл җирлегенең мордва Каратай авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2023 елның 24 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирел авыл җирлегенең Мордва Каратае авылында гражданнар җыены:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирел авыл җирлегенең мордва Каратай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (шул исәптән вак ташлар сатып алу, ташу, салу, грейдировкалау, юлларны кышкы чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр һәм аңа асмалы җиһазлар сатып алу);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән паркта җәяүлеләр юлын төзекләндерү, төзелеш материаллары сатып алу, язгы-көзге чорда чүп үләннәрен кисү, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр һәм аңа асмалы җиһазлар сатып алу);
- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (шул исәптән яктырткычлар, лампалар, таймерлар, исәпләгечләр, автоматлар, эшләтеп җибәрүчеләр сатып алу һәм урнаштыру).

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Мордва Каратай авылы, үзәк йорт 7, авыл клубы бинасы; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Кирел авыл җирлеге башлыгы Ф. Я. Зиннәтуллин